**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.11.2018 № 949

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының "Әтиләр советы" иҗтимагый советын төзү турында

"Татарстан Республикасында Әтиләр советы эшен активлаштыру турында"гы мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты киңәшмәсе беркетмәсен үтәү йөзеннән

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының "Әтиләр советы" иҗтимагый советын төзергә.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының "Әтиләр советы" иҗтимагый советы составын (1 нче Кушымта);
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының "Әтиләр советы" иҗтимагый советы турында нигезләмәне (2 нче Кушымта);
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы "Әтиләр советы" иҗтимагый советының чаралар планын (3 нче Кушымта).

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының 2016 елның 19 февралендәге 118 номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2018 ел, 20 ноябрь, 949 нчы

карарына 1 нче Кушымта

## Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы “Әтиләр советы” иҗтимагый оешмасының составы

| | |
|---|---|
| Совет рәисе: | Маняпов Линар Нурислам улы – Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Совет әгъзалары: | Ганиев Рәфис Габбас улы - Нурлат муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе башлыгы |
| | Мөкминов Рәсим Рауф улы – Нурлат шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| | Кәримов Идрис Гәбделбар улы «Нурлат АТП» сы генераль директоры, Нурлат муниципаль районында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил |
| | Сәгъдиев Айдар Рөстәм улы- “Нурлат район үзәк хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасының баш табибы |
| | Әбелханов Наил Барый улы - РМДН Нурлат муниципаль районы мөхтәсибе |
| | Имуков Василий Евгеньевич - ТР Казан епархиясе Нурлат шәһәре Ильин чиркәве православие дини оешмасы рухание |
| | Әюпов Әмир Салих улы - алкалы хоккей буенча балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенең “Ледок“ муниципаль белем бирү учреждениесе директоры |
| | Гыймадиев Илфат Илгиз улы - . Г. С. Хөсәенов исемендәге балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе директоры |
| | Хәсәнов Рөстәм Фәнир улы – Нурлат балалар сәнгать мәктәбе директоры |
| | Шадрин Юрий Александрович – шәхси эшмәкәр |
| | Тюкаев Шамил Равил улы - Г. С. Хөсәенов исемендәге "Балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе» МББОның футбол буенча тренеры. |
| | Федоров Алексей Иванович – “Татбурнефть" ҖЧҖ мотористы |
| | Миншин Айрат Минәхмәт улы – “Чулпан “ СК АҖ директор урынбасары |
| | Мифтахетдинов Илһам Набиулла улы – “Дойтаг" КСА бораулаучысы |
| | Тихонов Алексей Борисович – укытучы, ТР Нурлат шәһәре "9 нчы мәктәп” муниципаль белем бирү учреждениесе |

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты
2018 ел, 20 ноябрь, 949 нче
карарына 3 нче Кушымта

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы “Әтиләр советы” иҗтимагый Советының 2019 елга эш планы

| № т/с | Чаралар | Уткәрү вакыты | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Әтиләр советының 2019 елга эш планын раслау. Совет әгъзалары арасында бурычларны бүлү | гыйнвар | “Әтиләр советы” рәисе |
| 2. | Әтиләр советының I утырышы | гыйнвар | Әтиләр советы |
| 3. | Балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү Советы утырышларында катнашу | Ел дәвамында | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 4. | Имин булмаган гаиләләргә рейдлар (ата-аналар комитеты, хокук саклау органнары вәкилләре, мәгариф оешмалары вәкилләре, ББК һәм хокукларын яклау әгъзалары белән берлектә) | ел дәвамында | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 5. | “Хәрби хезмәткә чакырылучылар көне" чарасында катнашу | ел дәвамында | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 6. | Түгәрәк өстәл «Балалар тәрбияләүдә әти роле» | февраль | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 7. | Җиңү Көненә багышланган чаралар үткәрүдә катнашу | май | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 8. | «Мәңгелек яшәүче шөһрәт бар" аралашу сәгате (кайнар нокталарда, вакыйгаларда катнашучылар, ветераннар, Россия армиясе һәм флоты хезмәткәрләре белән очрашу) | май | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 9. | “Менә ул безнең җәй" фотоконкурсы | Июнь-август | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 10. | Балаларны яклау көнен үткәрүдә катнашу | 1 июнь | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 11. | “Нурлат районында ир-атлар | июль | “Әтиләр советы” әгъзалары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | арасында авыручылар санының һәм үлем санының төп сәбәпләре” түгәрәк өстәл | | |
| 12. | “Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит" акциясендә катнашу | август | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 13. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча идарәсендә исәптә торучы затлар һәм иректән мәхрүм итү урыннарыннан чыгучы затлар белән профилактик чараларда катнашу | ел дәвамында | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 14. | Спорт ярышлары: "Бергә-тату гаилә». Саф һавада ярышлар | сентябрь | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 15. | Балалар-ата-аналар мөнәсәбәтләре буенча ата-аналар өчен түгәрәк өстәл | сентябрь | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 16. | Юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау буенча акция үткәрүдә катнашу | Сентябрь-октябрь | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 17. | “Гаилә башлыгы - заманча ир-ат образы" түгәрәк өстәл | ноябрь | “Әтиләр советы” әгъзалары |
| 18. | Советның эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту | ел дәвамында | Гиняева Р. Ә. – "Татмедиа” "Нурлат-Информ» филиалы директоры |
| 19. | Әтиләр советының йомгаклау утырышы | декабрь | Әтиләр советы |

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты
2018 ел, 20 ноябрь, 949нчы
карарына 2 нче Кушымта

# Нурлат муниципаль районы Әтиләр советы турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Нурлат районы Әтиләр советы (алга таба – Совет) Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты каршында төзелгән коллегиаль киңәшмә органы булып тора, ул ата - аналар җәмәгатьчелегенең дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән социаль-тәрбия мохитен яхшырту буенча үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү, балаларны, яшүсмерләрне һәм гаиләләрне җәлеп итеп, профилактик, агарту, спорт һәм мәдәни-үстерү эшен оештыру, хәрби-патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирүне активлаштыру максатларында оештырыла.

1.2. Совет үз эшчәнлегендә Бала хокуклары турында конвенциягә, Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Совет, хәбәрдарлык, бәйсезлек, законлылык принципларына таянып, иҗтимагый башлангычларда үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

1.4. Үз эшендә Совет җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасының муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре, бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау өлкәсендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка учреждениеләр һәм оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

## 2. Советның төп максатлары һәм бурычлары

Совет эшчәнлегенең максаты булып ата-аналарның гаилә статусын һәм җаваплылыгын күтәрү, гаилә институтын ныгыту, гаилә мөнәсәбәтләренең рухи-әхлакый традицияләрен торгызу һәм саклау тора.

2.1. Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау.

2.2. Гаилә институтын һәм гаилә кыйммәтләрен ныгыту, балаларны тәрбияләү өчен ата-аналарның җаваплылыгын арттыру, гаиләләр белән профилактик эш оештыру.

2.3. Халыкның ирләр өлешен балалар һәм яшүсмерләр арасында күзәтүсезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау эшенә кертү. Ата-аналар җәмәгатьчелегенең рухи, әхлакый, мәдәни, физик, хезмәт һәм сәламәт яшәү рәвеше культурасын формалаштыру буенча педагогик потенциалын көчәйтү.

2.4. Социаль ярдәм һәм балаларны җәмгыятьтә тормышка яраклаштыру, үз-үзләрен девиант тотышы булган яшүсмерләр белән эшне оештыру. Белем бирү учреждениеләренә тәрбия процессы белән идарә итүдә ярдәм күрсәтү.

2.5. Халыкта ата-ана бурычларын үтәүгә җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру буенча башка социаль институтлар, иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү.

2.6. Җәмгыятьтә гражданлык татулыгына, тотрыклылыгына һәм тынычлыкка ирешү.

## 3. Совет Компетенциясе

3.1. Совет үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен хокуклы:

- гаиләгә, аналарга, ата-аналарга һәм балаларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән озак сроклы максатчан программалар һәм башка хокукый актлар проектларын эшләүдә катнашу;
- юридик һәм физик затлардан үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алу;
- үз эшенә каралган мәсьәләләр булган белгечләрне, экспертларны җәлеп итү;
- Совет компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча чараларда катнашу;
- гамәлдәге законнар нигезендә башка чараларны гамәлгә ашыру.

## 4. Совет эшен оештыру тәртибе

4.1. Совет иҗтимагый башлангычларда эшләүче Совет рәисеннән, урынбасарыннан һәм әгъзаларыннан тора.

4.2. Совет эшчәнлеге белән Нурлат районы Башкарма комитеты арасында турыдан-туры хезмәттәшлекне гамәлгә ашыручы Совет рәисе җитәкчелек итә.

4.3. Совет составына аталар (балаларның законлы вәкилләре) керә.

4.4. Совет утырышы беркетмәсе утырыш секретаре тарафыннан алып барыла, ул Советның беренче утырышында аның әгъзалары арасыннан рәис тарафыннан билгеләнә.

4.5. Совет карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, секретарь тарафыннан имзалана һәм Совет рәисе тарафыннан раслана. Совет карарлары тәкъдим итү характерында була.

4.6. Совет утырышлары кирәк булганда, әмма елга ике тапкырдан да ким булмаска тиеш. Совет утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы була. Утырыш нәтиҗәләре буенча Совет утырышларда катнашучыларның күпчелек тавышы белән карар кабул итә.

4.7. Совет үз эшчәнлеген Совет утырышында ел саен кабул ителә һәм аның рәисе тарафыннан раслана торган эш планы нигезендә гамәлгә ашыра.

4.8. Планлы чараларның үтәлешен Совет рәисе контрольдә тота. Совет үткәрә торган план чараларының нәтиҗәләре беркетмәләр, белешмәләр, рәсми язма рәвешендә рәсмиләштерелә.

4.9. Совет утырышлары беркетмәләре, аның эшчәнлеген регламентлаучы башка документлар рәистә саклана.

5. Совет эшчәнлеген туктату аның әгъзаларының гади күпчелеге инициативасы белән Башкарма комитетның мәҗбүри язма хәбәр итүе белән гамәлгә ашырыла.